ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» 12 2021г.** **№1123**

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 14 июлендәге «2021 елга Ютазы муниципаль районының бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәрен һәм максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 538 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2021 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11декабрендәге 1130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 8 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга Ютазы муниципаль районы бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында»гы 2021 елның 14 июлендәге 538 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктны өстәргә:

   «1.1.Ютазы муниципаль районы бюджет учреждениеләре тарафыннан административ-идарә персоналының хезмәт хакын түләүгә, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәреннән җибәрелә торган чыгымнар күләме, әлеге карарның 1 пункты нигезендә хезмәт хакын түләүгә юнәлдерелә торган

күрсәтелгән керемнәр күләменең 30 процентыннан артмаска тиеш дип билгеләргә”;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.С. Рузановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С.П. Самонина

А. В. Сучкова
8(85593)2-80-12